**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Татар Димскәе авыл җирлеге составына керүче татар Димскәе авылында халык җыены карары**

**17 декабрь 2021 ел № 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Татар Димскәе авыл җирлегенең Татар Димскәе авылында гражданнар җыены

Карар итте:

1. 2022 нче елда гражданнарның үзара салымын Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Татар Димскәе авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кеше өчен, 1 нче төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучыларның тол хатыннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән һәм күп балалы гаиләләрдән кала, 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә.
2. Җыелган акчаларны Татар Димскәе чишмәсенә капиталь ремонт ясау өчен тотарга.

**Халык җыенында рәислек итүче,**
**Татар Димскәсе авыл җирлеге башлыгы Л. А. Хәбирова**
**а**